**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru:

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**«03» август 2019 ел** **№11**

ТР Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге территориясендә гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пункты төзү турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы һәм «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү турында Нигезләмәне раслау турында» 2000 елның 2 ноябрендәге 841 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 21 маендагы 1126-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын төзү турында» 2019 елның 3 июлендәге 283 номерлы карары белән һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Уставының 45, 72 статьяларына таянып **КАРАР БИРӘМ**:

1. «Мордва Афонькәсе авыл мәдәният йорты» МБУ базасында Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пункты (алга таба-Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП) булдырырга. Укыту-консультация пункты җитәкчесе итеп авыл мәдәният йорты директорын билгеләргә.

2. ГО буенча УКП консультантларын билгеләргә:
- авыл мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе;
- Лагерка авылы буенча «Җирлекара үзәкләштерелгән китапханә» МБУ 10нчы номерлы филиалы китапханәчесе;

3. Оештыру чорында «Мордва Афонькәсе авыл мәдәният йорты» МБУ филиалы директорына Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Т.В. Кәримуллин тарафыннан расланган «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре район мәдәният йортлары һәм авыл клублары базасында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктларын оештыру һәм төзү буенча методик рекомендацияләр»гә катгый рәвештә таянып эш итәргә.

4. Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү тематикасы буенча кирәкле укыту - методик, күрсәтмә һәм өләшү материаллары белән стендны бизәү (оформление) һәм почмаклар сатып алу Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитеты акчасы хисабына башкарыла.

Авыл мәдәният йорты бинасында «Гражданнар оборонасы һәм халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча уку-консультация пункты» дип аталган элмә тактасын әзерләргә һәм урнаштырырга, аның эш вакытын күрсәтеп. Консультация хезмәтләре күрсәтүне атна саен» 16.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә

Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге
башкарма комитеты
Җитәкчесе А.И. Митяев